ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 1 өлешендәге 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“10) законлы нигезләр булмыйча торып, ул чакыру комиссиясе бәяләмәсе нигезендә чакырылыш буенча хәрби хезмәт узмаган дип танылса (контракт буенча хәрби хезмәт узган гражданнардан тыш), – Россия Федерациясе тиешле субъектының чакыру комиссиясенә күрсәтелгән бәяләмәгә шикаять бирү өчен билгеләнгән вакыт тәмамланган көннән алып 10 ел дәвамында, әгәр Россия Федерациясе тиешле субъекты чакыру комиссиясенең әлеге бәяләмәсе һәм (яисә) карары гражданның шушы бәяләмәгә шикаяте буенча судка бирелгән булса, – Россия Федерациясе тиешле субъектының чакыру комиссиясе бәяләмәсе һәм (яисә) карары чыгарылганда гражданның күрсәтелгән бәяләмәгә шикаять бирү хокуклары бозылмаган дип тану турындагы суд карары үз көченә кергән көннән алып 10 ел дәвамында”;

2) 33 статьяга түбәндәге эчтәлекле 15 өлеш өстәргә:
“15. Муниципаль хезмәткәргә карата ышанычны югалтуга бәйле эштән азат итү рәвешендәге җәзаны куллану турындагы белешмәләр муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт узган җирле үзидарә органы тарафыннан “Коррупциягә каршы тору турында” Федераль законның 15 статьясында каралган ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестрына кертелә.”;

3) 42 статьяның 4 өлешендә “2018 елның 1 гыйнварына” сүзләрен “2020 елның 1 октябренә” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 15 статьясындагы 1 өлешенең 10 пункты нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) 2014 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 14 декабрь
№ 90-ТРЗ